ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

“Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы” Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вакытлы басмасы турында нигезләмәне раслау хакында” 2013 елның 23 маендагы 2924-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. “Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы” Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вакытлы басмасы турында нигезләмәне раслау хакында” 2013 елның 23 маендагы 2924-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары белән расланган “Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы” Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вакытлы басмасы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) VI бүлекнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8. Басма өч бүлектән тора:

1) беренче бүлектә Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарлары бастырыла;

2) икенче бүлектә Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәләре бастырыла (Дәүләт Советы Рәисенең яисә Дәүләт Советы Секретаренең тиешле карарлары нигезендә);

3) өченче бүлектә Дәүләт Советы яисә аның Президиумы тарафыннан кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына шикаять белдерү турындагы эшләр буенча суд карарлары яисә бастырып чыгару законнар нигезендә мәҗбүри булган мондый карарлар хакында белдерүләр бастырыла.”;

2) VIII бүлектә:

а) 17 пунктта “Дәүләт Советы Аппаратының Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итү бүлеге,” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 18 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“19. Дәүләт Советы Аппаратының Документлар белән тәэмин итү идарәсе әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә түбәндәге функцияләрне башкара:

1) “Җыелма басманы” Дәүләт Советының матбугат басмаларын чыгару планына кертү турында тәкъдимнәр әзерли, басмаларны бастырып чыгару өчен әзерләү кагыйдәләрен билгели торган гамәлдәге норматив-техник документлар нигезендә басманы әзерләүне һәм чыгаруны гамәлгә ашыра;

2) басманың һәр номерын формалаштыра (туплый), җыю эшләре башкара;

3) басманың чираттагы номерының оригинал-макетын әзерли;

4) оригинал-макетка, документларның төп нөсхәләре белән чагыштырып, корректор төзәтмәләре кертә;

5) “Җыелма басманы” чыгару шартларын үзгәртү турында тәкъдимнәр кертә;

6) “Җыелма басманың” тиражын билгели;

7) “Җыелма басма” номерын тираж әзерләү өчен Дәүләт Советы Аппаратының Эшләр идарәсенә җибәрә;

8) тиешле полиграфик дәрәҗәдә басманы әзерләү һәм чыгару срокларының үтәлешен тикшереп тора;

9) “Җыелма басманы” таратуны оештыра.”;

3) X бүлекнең 24 пунктында “19 пунктның 3 пунктчасын” сүзләрен “19 пунктның 6 пунктчасын” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2016 елның 1 ноябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2016 елның 26 октябре
№ 1425-V ДС